# Татар халкының милли киемнәре һәм бизәнү әйберләре.



# Бизәнү әйберләре

- Балдак-кольцо.
- Йөзек-перестень.
- Беләзек-браслет.
- Алка-серьги.
- Чулпы-накосник.
- Чәч тәңкәсе-
- монета для волос.





# Сораулар.

- Татар кызының нинди милли бизәнү әйбер-ләре бар?

  Сиңа бизәнү әйберлә-ре ошыймы?

  Дус кызыңның нинди бизәнү әйберләре бармы?



# Татар халкының милли киемнәре.

- Татар халкы элек-электән бик матур киенергә яраткан.Чигелгән түбәтәйләре, берсеннән-берсе матур калфаклары, бизәкле читекләре

  белән дан тотканнар.

  Татар хатын-кызлары милли бизәкләр белән чигелгән алъяпкычлар кигәннәр.

  Үзенчәлекле матур күлмәкләрне, камзулларны
- татар халкы аеруча ятатып кигән.

# Калфакла р.



Татар хатын-кызлар

алтын  яки көмеш

белән бизәлгән ,төрле чигүле,

бизәкле  калфаклар кигәннәр.

Калфаклар бәрхеттән тегелгән.

төрле милли бизәк-ләр белән чигелгән.









- Татар халкының яраткан композиторы Сара Садыйкова калфаклар кияргә бик яраткан.Аны халык яратып, “калфаклы сандугач” дип йөрткән.



# Түбәтәйләр.





# Түбәтәйләр .

- Борын-борыннан ир-егетләр түбәтәй кияргә яратканнар. Көндә кия торган түбәтәйләрне карарак төстәге тукымадан тегкәннәр.Бәйрәмнәрдә кияр өчен ефәк, парча,бәрхеттән теккәннәр.Байлар энҗеле яки алтын-көмеш җепләр белән чигелгән түбәтәй киюне дәрәҗә санаганнар.



Читекләр.







# Читекләр.

- Татар халкының аяк киемнәре күп төрле.

Читекләрне ир-егетләр дә,хатын-кызлар да

кигәннәр.Ирләр читеге кара күннән,йомшак

итеп тегелгән.Яшь хатыннар һәм кызлар

биек үкчәле каюлы читекләр киергә яраткан.